XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Әхмәд Мидхәт әфәнде шәхесе һәм иҗаты татар мәгърифәтчеләре, зыялылары арасында аеруча популяр була. Ике йөзьеллык чигендә дүрт хикәясенең, татар теленә тәрҗемә ителеп, Оренбург һәм Казан типографияләрендә басылып чыгуы язучы фикерләренең, мәгърифәтчелек идеяләренең Русия мөселманнарына якынлыгы, рухи ихтыяҗларына җавап бирүе турында сөйли [1]. Аның 1897 елда «Яшьлек җүләрлек» дигән хикәясе, С.Максуди тарафыннан татарчалаштырылып, Казанда дөнья күрә. 1902 елда Оренбургта «Яшь егетләр өчен гаять файдалы бер хикәят» дигән хикәясе, ә Казанда бертуган Кәримовлар матбагасында дидактик характердагы «Кыйссадан хисса» китабы нәшер ителә. Әхмәд Мидхәтнең «Бозудан дару» һәм мәшһүр төрек философы Әхмәд Мәхмүт әфәнденең «Хыял вә хакыйкать» нам әсәренең тәрҗемәсе» әсәре Ш.Мостафа тәрҗемәсендә Казанда 1908 елда басыла.

Шушы чорда аның тормыш юлын һәм күпкырлы эшчәнлеген гыйльми күзаллау юнәлешендә дә җитди адымнар ясала. Әхмәт Мидхәт белән шәхси аралашып, аның гыйльми һәм рухи тәрбиясен алган Фатих Кәрими үзенең публицистик язмаларында, сәяхәтнамәләрендә һәм хатларында бу олы шәхеснең характер сыйфатлары, кардәш халыкларга уртак теләк-омтылышлары һәм иҗтимагый-фәлсәфи хезмәтләре белән татар укучыларын таныштыра [2]. Танылган шәрык һәм дин белгече, галим, мәгърифәтче язучы Ризаэтдин Фәхретдиннең 1913 елда Оренбургта «Мәшһүр ирләр» сериясендә Ә.Мидхәтнең тормыш юлын, әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеген яктырткан «Әхмәт Мидхәт әфәнде» [3] монографиясе нәшер ителә. Г. Ибраһимов исә үз мәкаләләрендә төрек әдәбияты, иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихында галим һәм әдипнең ролен, аның киңкырлы эшчәнлеген югары бәяли. Төрек әдәбияты тәхетенә, иң беренче чиратта, ул Әхмәд Мидхәтне утырта [4]. Әхмәд Мидхәт әфәнденең 1912 елда үлеменә нисбәтле татар вакытлы матбугат битләрендә басылган кайгы язмалары, мәкаләләр дә бу галимнең зурлыгын аңлауга һәм рухи мирасының аерым аспектларын гыйльми күзаллауга үзләреннән мәгълүм өлеш кертәләр [5].

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң, социалистик идеологиянең сәнгатькә, шул исәптән әдәбиятка да көчле йогынтысы аркасында, әдәби-мәдәни бәйләнешләр һәм үзара тәэсир итешү тыгыз булуга карамастан, төрек әдәбиятын, аның күренекле шәхесләре иҗатын тикшерү зәгыйфьләнә, ә алга таба ул бөтенләй сүнеп-сүрелеп кала. XX гасыр ахырында Советлар берлегендә, үзгәртеп кору хәрәкәте башланып, сүз ирege һәм фикер хөрлеге игълан ителү белән, бу юнәлештә җанлану күзәтелә. Кискен иҗтимагый-рухи алмашыну елларында нәшер ителгән М.Мәһдиевнең «Социальные корни таланта» (1990) хезмәтендә татар халкының яңарышында зур роль уйнаган Әхмәд Мидхәт шәхесенә һәм аның әдәби эшчәнлеге, аның Фатих Кәрими белән мөнәсәбәтләре хакында шактый тулы мәгълүмат урнаштырыла [6].

XX гасыр ахырында төрек әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнүдә сыйфади үзгәрешләр барлыкка килеп, төрки-татар әдәби бәгланышлары чагыштырмалы-тарихи планда тикшерелә башлый. Әдәбият галиме, шәрык белгече Х. Миңнегуловның монографик хезмәтләрендә һәм аналитик мәкаләләрендә, беренчедән, XIX – XX гасыр чикләрендә татар галимнәренең әдәби багланышлар проблемасы белән кызыксынуы, бу юнәлештә хезмәтләр басылып чыгуы хәбәр ителсә, икенчедән, бу чорда татар халкының иҗтимагый-рухи яңарышына йогынты ясаган күренекле шәхесләр арасында Әхмәт Мидхәткә югары бәя бирелә [7].

Р.Харрасованың, тарихи дөреслек торгызылып, исеме һәм киңкырлы мирасы үз халкына, Ватанына кайтарылган мәшһүр язучы, драматург һәм ялкынлы публицист Гаяз Исхакыйның башлангыч чор прозасын әдәби багланышлар яссылыгында яктырткан «Әдәбият бәйләнешләр яктылыгында» [8] монографик хезмәтендә Әхмәт Мидхәтнең бай әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге, татар зыялылары белән рухи бәйләнешләре, милли сүз сәнгате һәм иҗтимагый фикере күтәрелешендәге урыны, язучы әсәрләренең аерым сыйфатлары хакында нәзари фикерләр тагын да тирәнәя. Шушы елларда татар әдәбият белемендә татар-төрек әдәби бәйләнешләрен

системалы тикшерү юнәлешендә тагын да җитдирәк адымнар ясала. А.Нигъмәтуллинаның «Татарско-турецкие литературные связи конца XIX – начала XX века» (на материале жизни и творчества турецкого писателя-просветителя Ахмета Мидхата)» [9] хезмәте татар әдәбияты фәнендә Әхмәт Мидхәт әфәнденең тормыш сукмаклары һәм мирасын монографик тикшерүне яңа баскычка күтәрә. Биредә, беренчеләрдән булып, мәгърифәтче галимнең, язучы һәм философның фәнни иҗат биографиясе тудырыла һәм Әхмәт Мидхәтнең иҗтимагый, фәлсәфи һәм әдәби-эстетик карашлары шәрык һәм гареб контекстында анализланып, рухи мирасы билгеле бер дәрәҗәдә тәмамланган төс ала. И.Мөхәмәтовның «Книга Мухаммеда Челеби «Мухаммадия» в контексте татарско-турецких литературных взаимосвязей» (2006) [10] дигән фәнни хезмәтендә XIII – XIX гасырлар арасында татар-төрек бәйләнешләре гыйльми күзалланып, татар әдәбият белемендә мәдәни багланышларның барлыкка килү һәм үсеш баскычларының тулы картинасы күрсәтелә.

## 2. «Хаҗә-и әүвәл»гә карата булган ышаныч һәм ярату»

Идел-Урал буе төркиләре арасында Әхмәт Мидхәт Әфәнде кадәр мәгълүм һәм мәшһүр булган башка бер төрек язучысы да юк, шул сәбәпле, аның вафаты турындагы хәбәр биредә бик тиз тарала һәм халыкны кайгыга сала. Газета-журналларда үлем кайгысын уртаклашкан хәбәрләр һәм әдипкә багышланган истәлек язмалары күпләп басыла. Беренче чиратта, баш мөхәррире Фатих Кәрими булган «Вакыт» газетасы, «Тәрҗеман», «Идел», «Себер», «Кояш», «Йолдыз» һәм «Шура» кебек газета-журналлар аның шәхесе зурлап язылган мәкаләләр бастыралар. Ә. Мидхәт әфәнденең вафаты хәбәрен ишетеп, мәктәп-мәдрәсәләрдә укучы шәкертләр, алдынгы гаиләләрдә тәрбияләнеп, әсәрләренең әдәби сүз тәмен тоюга ирешкән кыз балалар аның рухына Коръән укыйлар, хәтем чыгалар.

Гомере буе ару-талуны белмәгән Әхмәт Мидхәт әфәнде ике йөздән артык әсәре белән, «белгәннәрен башкаларга җиткерү омтылышы» аша китап дигән хәзинәне, Госманлыда да, Идел-Урал буйларында да, мәдрәсәләргә һәм галимнәргә генә аталган затлы нәрсә булудан туктатып, халык массаларына ирештерү өчен күп көч куйган. Шуңа күрә дә «хаҗә-и әүвәл»[1] исеме аңа бик килешеп тора. Әдипнең «Мөдафага вә мукабәлә» («Каршы тору һәм җавап кайтару») исемле өч томлык әсәре Идел-Урал буе төркиләре тарафыннан бик үз ителгән. Бу әсәрне дәвамлы тикшергән һәм өйрәнгән бер галимнең: «Әгәр кыямәт көнендә Рәсүлуллаһтан тыш тагын берәүдән шәфәгать теләү мөмкин булса, мин, һичшиксез, Әхмәт Мидхәт Әфәндедән теләячәкмен» [2: 97] дигән сүзләре аңа булган ышанычның һәм мәхәббәтнең дәрәҗәсен күрсәтә. Фикри һәм рухи яктан таянычка мохтаҗ булган Идел-Урал буе төркиләре тарафыннан Ә.Мидхәтнең үз ителүенә бигрәк тә аның Европага карашы һәм христиан миссионерлар белән мөгамәләсе сәбәп була. Зәки Вәлиди үз истәлекләрендә Ә.Мидхәт әсәрләренең Джон Драпер кебек европалыларга һәм рус китапларына каршы агу китәргеч кебек кабул ителүен яза [11: 82]. Ә. Мидхәт, «Гаребне үзендә эретеп, туры юлга керер дәрәҗәгә китергәннән соң, аны мөселманлашкан йөзе белән укучыларына тәкъдим итә» [12: 76]. Танпынар сүзләре белән әйтсәк: «Ә. Мидхәт, мәдәният кризисы баласы булуын беркайчан онытмый. Исламиятне христианлык алдында яклау өчен, «Мөдафага вә мукабәлә» («Каршы тору һәм җавап кайтару») әсәрләрен язган галим бөтен хезмәтләрендә диярлек бу кризиска кире әйләнеп кайта» [13: 472]. Аның бу ягы, һичшиксез, Зәки Вәлидинең атасына гына түгел, бик күпләргә ошый.

Ә.Мидхәтнең замандашы булган Шәмсетдин Сами да «Камус-и түрки» һәм «Камусу-ль аләм» исемле хезмәтләре белән Идел-Уралда гыйлем әһелләре тарафыннан танылa, аеруча алты томлык энциклопедик әсәренә зур бәя бирелә. Ләкин аның хезмәтләренең Ә.Мидхәт әфәнденекенә караганда житдирәк һәм гыйльмирәк булуы «хикәя» кебек җиңел аңлашыла һәм мәшәкатьсез укыла торган әйберләргә гадәтләнгән халык арасында тарала алмауга сәбәп була. Беренче төрек романнары булып саналган «Тәгашшук-и Тәлгать вә Фитнат» [14] һәм «Хатунлар» [15] кебек халыкка атап язылган әсәрләренең тәрҗемәләре басылган булса да, Ш. Сами фикеренчә: «Хезмәтләрендә исламиятнең югары фикерләрен һәм дин хикмәтләрен алга сөрүче, гыйлемнәрне һәм фәннәрне, мәдәниләшүне һәм тәрәккыятне

[1] Хаҗә-и әүвәл – милләтнең гыйлемдә һәм фикердә алга китүе өчен зур тырышлык күрсәткән шәхес.

һәрвакыт дин белән килештерергә тырышучы» [2: 97] Ә.Мидхәткә өстенлек бирүгә китерә.

Әсәрләрен язган вакытта, Шинасинең саф төрек теле турындагы фикерен яклавы, әлбәттә, Ә.Мидхәт әсәрләренең аңлашылу дәрәҗәсен арттырган. 1880 еллар башында «Вакыт», «Әл-Лива» һәм «Әл-Мүәид» газеталарын укыган Ризаэтдин Фәхретдин: «Әгәр бүген Мөслим Әл-Хорасани яки Фируз Абади каберләреннән торып чыгып, «Әл-Лива» белән «Әл-Мүәид» газеталарының соңгы саннарын укысалар, алар да минем кебек һичбер нәрсә аңламаячаклар» [16: 19] дип тәнкыйтьли. Әхмәт Мидхәтнең теленең сафлыгы, алда әйтелгәнчә, аның милләттәшләре тарафыннан да бик җиңел укылуын тәэмин итә [17: 38-40].

**3. Сәяхәт иткән Истанбул китаплары**

Истанбул зыялыларының китаплары Идел-Урал буе төркиләре арасында кайсы заманнардан бирле тарала башлаганлыгы турында ачык кына мәгълүмат юк. Шулай да «Мөхәммәдия», «Әнвәрү-л гашыйкин», «Алты пармак», «Мәгърифәтнамә» һәм «Тарикат-е Мөхәммәдия» кебек бу җирләрдә шактый билгеле булган классик дини әсәрләрнең, 1552 елда Явыз Иван тарафыннан Казан алынганнан соң, Дагыстанга һәм аннан Төркиягә качкан һәм соңрак бер өлеше ватанына кире кайткан халык белән таралуы хакында фикер ныклап урнашкан [18: 283].

XIX гасырның ахырларына кадәр Бохара мәдрәсәләренә укып, илләренә кире кайткан яшьләрнең, «паспорт», «эш кенәгәсе» кебек (бу гыйбарәләрне Р. Фәхретдин файдаланган) кулларыннан да төшерми торган китаплар арасында, алда телгә алынганнар белән беррәттән, «Тәфсир-и тыбъян», «Лөгат-е ахтәри» һәм Әхмәт бин Муса әл-Хаялинең «Шәрх-е гакаид хашиясе» кебек әсәрләрне күрсәтергә мөмкин [3: 119]. Алай гына да түгел, Мәхкәмә-и-шаргыя Оренбурджыя мөфтие Габдессаләм Габдерәхимев, Сәгыйть Алкин һәм Ибраһим Хәлфин кебек галимнәрнең бу әсәрләрнең теленә һәм өслүпләренә ияреп язганлыклары да күренә [3: 120]. Югарыда исемнәре телгә алынган китаплар киң таралу алса да, авторларының танылмавы һәм хәтта төрек галимнәре икәнлеге игътибарга алынмавы бик кызыклы. Бу – Госманлы дәүләтендә дә нәкъ шулай. Мәсәлән, мәшһүр «Мөхәммәдия»нең авторы Языҗыугълы хакында Шәмсетдин Саминең «Камусу-ль галәм»ендә дә бик аз мәгълүмат бирелгән. Идел-Урал регионындагы мәдрәсәләрдә дәреслек буларак укытылган «Мөхәммәдия» мәшһүр татар шагыйре Габдулла Тукайга пародия язар өчен илһам чишмәсе булган бер вакытта [19: 84], Госманлы дәүләтендә Абделхәмид II тарафыннан бу әсәрне уку тыела. Ризаэтдин Фәхретдин Языҗыугълына карата мондый мөнәсәбәтне берничек тә аңлый алмавы турында яза [3: 34].

1727 елда Госманлыда нәшриятның барлыкка килүе Истанбулда басылган китапларның Идел буенда да таралуына сәбәп була. XVI гасырның ахырында Россиядә барлыкка килгән нәшрият, гәрчә Петр I Манифесты татар телендә 1722 елда нәшер ителсә дә, Идел-Урал буе төркиләре тарафыннан бары тик XVIII гасыр ахырларында гына, Павел I нең 1799 елда 20823 номерлы фәрманы чыкканнан соң, «дини китаплар» нәшер итү өчен генә файдаланыла башлый [20: 134]. 1762 елның 18 февралендә игълан ителгән «Дворянннарның иреге турында Манифест» фәрманы белән шәхси нәшриятлар ачарга рөхсәт ителә. Татарлар, Екатерина II гә гаризалар язып, мәдрәсәләрдә укытыр өчен, дәреслек китапларның азлыгыннан зарланалар. Бу өлкәдә алга китеш сизелә башлаганнан соң, вәзгыятьне контрольдә тоту максатында, 1783 елда игълан ителгән фәрман юкка чыгарылып, бөтен шәхси нәшриятлар ябыла. Екатерина патшабикә, киеренкелекне беркадәр йомшарту өчен, 1787 елда дәүләт казнасы хисабына гарәп хәрефләре белән 477 битлек «Коръән-е Кәрим» бастыра. Аның 1788 елның 22 сентябрендә чыгарылган фәрманы белән Уфада Русия мөселманнарының (Кырымнан башка) Мәхкәмә-и-шаргыя Оренбурджыя (Диния нәзарәте) ачыла. Бу адымнар, һичшиксез, хәлифәт мәркәзе булган Истанбул белән Россия мөселманнарының бәйләнешләрен киметү максатыннан ясала.

Казанда мөселманнар өчен оештырылган нәшриятта цензура көчле булу сәбәпле, Идел-Урал буе төркиләре Истанбулдагы матбагаларны файдаланалар. Госманлы нәшриятының беренче әсәрләреннән 1727 елгы Мөтәфәррика басмасы булган «Ванколы лөгате» һәм 1730 ел басмасы булган «Җиһаннамә» ләр бүгенге көндә дә Казан университеты китапханәсендә саклана [20: 134]. Ризаэтдин Фәхретдин дә шәкертлек елларында бу әсәрләрдән шактый киң файдалануын белдерә [21: 417-419].

## 4. Төрки дөньяның көнбатышы – Истанбул

Истанбул басма китапларының бу төбәккә килеп җитүендә сәүдәгәрләрнең, сәяхәтчеләрнең һәм бигрәк тә Истанбул аша хаҗ сәфәре кылучыларның зур өлеше бар. Барыннан да әһәмиятлесе шул: барлык каршылыкларга карамастан, татарларның аң-белемгә, мәктәп-мәдрәсә ачуга омтылышлары бу китап агымын көчәйтә. Сәфәрдән кире кайтучылар сандык-сандык китаплар алып кайталар. Нәкышбәнди шәехе Гүмүшханәвинең хәлифәләреннән татар шәехе Зәйнулла Рәсүли, 1859 елда кылган хаҗ сәфәреннән кайтканда, Истанбулда шулкадәр күп китап ала ки, хәтта акчасы калмый, иленә кайтырга дип кайбер китапларны кире сатарга мәҗбүр була [22: 20]. Хаҗга барган галимнәрнең сәяхәтнамәләр язулары һәм Истанбулга багышланган өлешләренең тәфсилле һәм тәэсирле тасвирланышы хәлифәт мәркәзендәге алгарыш һәм галимнәр белән кызыксынуны арттырган. Мәсәлән, мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗани 1880 елда хаҗга барышлый Истанбулда туктап, шәйхелислам Хәсән Осман Фәһми, Мүниф паша, Җәүдәт паша һәм тагын берничә галим белән күрешүен «Рихләтү-л Мәрҗани»дә теркәп калдырган [18: 178-179]. Риза Фәхретдин моңа охшаш тагын 13 сәяхәтнамә булуын һәм аларның исемнәрен яза [18: 144-146]. Ул 1851 елда кылынган бер сәяхәтнең кульязмасын табып өйрәнә һәм «Исмәгыйль сәяхәте» исеме белән бастырып чыгара [23]. Боларның барысы да Идел-Урал буе укучысын Истанбулга якынайта. «Истанбулны бер күрсәм, үкенмәс идем үлсәм дә» гыйбарәсенең төрки дөнья аңында киң таралуы һәркемнең Истанбулны күрү хыялы белән яшәгәнлегенә дәлил [24: 232-234].

XIX гасырның урталарында җәелә башлаган газетачылыкны кызыксынып күзәтүчеләр биредә дә күренә башлый. Истанбулдан алып кайтылган газета һәм китаплар Идел-Урал буенда «Аурупа мәгърифәтчелеге» фикеренең уянуына китерә. Намык Кәмальнең, Әхмәт Мидхәт әфәнденең әсәрләре Казанда да басыла башлый [25: 106]. 1881 елда Ә. Мидхәт әфәнденең «Тәрҗеман-ы хакыйкать»ен биредә дә укыганнар. Бу елларда әле Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман»ы чыкмый. Оренбург бае Шакир Рәмиев Истанбулдагы энесе Закир Рәмиевкә 1881 елның 16 мартында язган хатында «Тәрҗеман-ы хакыйкать»не бик яратып укуын хәбәр итә һәм газетаны даими җибәреп торуын үтенә [3: 122]. Бу төбәкнең алдынгы җәдитчеләренең берсе Ризаэтдин Фәхретдиннең «Тәрҗеман»белән танышлыгы бары тик 1884 елда 27 саны белән башланса, Истанбулдан китерелгән «Вакыт», «Әл-лива» һәм «Әл-мүәид» газеталары белән ул алдан таныш була һәм аларны укып бара [16: 19]. Чынбарлыкта И. Гаспралының «Тәрҗеман»ы мәркәзе Истанбулда булган җәдитчелек фикерен көчәйтеп җибәргән һәм тел якынлыгы аша бу фикерләрне җәелдергән генә.

XIX гасыр, һичшиксез, Госманлы Төркиясендә һәм төрки дөньяда иҗтимагый-рухи һәм мәдәни яңарыш ихтыяҗы бик нык хис ителгән чор була. Госманлы бу мәсьәлә белән дәүләт күләмендә шөгыльләнгән, сәяси идарә көченнән мәхрүм булган төрки дөнья исә аны шәхесләр дәрәҗәсендә һәм җәдитчелек исеме белән аталып йөртелгән хәрәкәт яссылыгында тормышка ашыра алган. Истанбул бу яңарышта төрки дөнья өчен мәркәз ролен табигый рәвештә үз өстенә ала. Кайбер совет чоры галимнәре дә Төркиянең бу мөһим ролен билгеләп үтәләр [26: 197]. Истанбулның хәлифәт мәркәзе булуы, алфавит һәм тел уртаклыгы, көнбатыш белән турыдан туры бәйләнештә торган Госманлы зыялылары белән чагыштырганда, бу тәҗрибәләрдән мәхрүм булган төрки дөнья зыялыларын, мәҗбүри рәвештә, Истанбулга юнәлтә.

## 5. Әхмәт Мидхәтнең Идел-Урал төркиләре белән кызыксынуы

Ризаэтдин Фәхретдин, төрки дөнья галимголямәләренең Истанбулга тартылулары көчле булса да, Госманлы зыялыларының Русиядәге диндәшләре һәм кардәшләре белән тиешенчә кызыксынмауларыннан зарлана. «Дивани шерхе»нә, «Тавзиһ вә гакаид-и нәсәфия»ләргә аңлатмалар язмаса да, «Мөстәфәдү-л әхбәр» авторы Мәрҗанинең исеме, һич булмаса, Әхмәт Мидхәт әфәнденең һәм Шәмсетдин Саминең әсәрләрендә генә булса да искә алынырга тиеш иде [3: 123-124]. Ә энциклопедия авторы Шәмсетдин Сами исә, Әхмәт Мидхәт белән чагыштырганда, тагын да битарафрак, чөнки Әхмәт Мидхәт Исмәгыйль Гаспралы, ахун Гатаулла Баязитов, Иосиф Готвальд һәм Гөлнар ханым (Ольга Сергеевна Лебедева) кебек Русия галимнәре һәм шәркыятьчеләре турында язган.

Әхмәт Мидхәт «Мәҗлис-и умур-ы сыххия»дә[2] әгъза һәм сәркатип булып эшләгән вакытында, ягъни 1884 елларда Госманлыдан

[2] «Мәҗлис-и умур-ы сыххия» - Сәламәтлек эшләре оешмасы

читтәге төрки халыклар, бигрәк тә Идел-Урал буе төркиләре белән ныклап кызыксына башлый. Бу оешма, билгеле булганча, хаҗга барганда, Истанбулга тукталган мөселманнарга карантин рөхсәте бирә торган була. 1876 елдан солтан сараена якынайган Әхмәт Мидхәт, Абделхәмит II нең сәясәтенә туры килерлек итеп, эшчәнлек алып бара, хәтта сарай белән булган мөнәсәбәттә актив роль уйный. Сәламәтлек оешмасына тукталган кешеләргә биргән нәсихәтләре, Истанбулга килгән яшьләргә Мәктәб-и мөлкиягә укырга керергә булышулары, гозерләр буенча Казанга «Тәрҗеман-ы хакыйкать» газетасын җибәреп торуы – ул башкарган эшләрне ачык күрсәтә.

Бу урында Сарайның «Тәрҗеман-ы хакыйкать»кә ярдәм итү сәбәбенә бераз ачыклык кертү сорала. Танпынар «Әхмәт Мидхәт – матбага ачып, аның эшләвен, алга китүен теләве белән эшмәкәр иде» [13: 457] дигән карашта торса да, Госманлыдан читтә, шул исәптән Русиядәге укучы массасына танылуга ирешкән Ә. Мидхәт, беренче чиратта, моны дәүләт файдасына кулланырга тырышкан миссионер була. Яңа укучы массасыннан канәгать булуы хакында ул Фатих Кәримигә 1892 елда язган җавап хатында белдерә: «Мин гаҗизгә бәян ителгән мәхәббәт вә игътибардан бик тә шатмын. Хезмәт итәргә теләгебез, безгә болай ерак җирләрдәге кардәшләребезнең дә мәхәббәтләрен, игътибарларын казандырганы өчен мәсләгебезгә булган рәхмәтебез тагын бер кат артты» [3: 60-61].

### 6. Әхмәт Мидхәтнең шәркыятьче (ориенталист) дуслары

Әхмәт Мидхәт 1889 елда Стокгольмда үткәрелгән VIII Шәркыятьчеләр конгрессында ике рус ориенталисты белән таныша. Боларның берсе – дуслыклары аннан соң да дәвам иткән Гөлнар ханым, икенчесе – профессор Иосиф Федорович Готвальд була. Алар белән танышуны ул Русия татарлары турында ни дә булса ишетү, белүнең бер юлы итеп карый [27: 22-23]. Бу хакта ул үзенең бер хатында: «Русиядәге мөселманнарның хәлләре мине һәрвакыт кызыксындырып тора. Сездән шактый мәгълүмат алып, бу мәгълүматымны никадәр киңәйтсәм, шулкадәр файдалы булачак. Мондый эчтәлекле хатларыгызны иренмичә, киресенчә, бик теләп һәм кабат-кабат укыячакмын» [3: 63-64], – дип яза. Конгресстан соң, аеруча Гөлнар ханым белән бәйләнешләре дәвам итә. Гөлнар ханым Истанбулга килгән вакытларында Ә.Мидхәтнең кунагы була.

Француз галиме Эрнест Ренанның «Ислам һәм тәрәкъкый» әсәренә Петербург имамы ахун Гатаулла Баязитов рус телендә язган «Ренанга рәддия» китабын Гөлнар ханым һәм «Тәрҗүман-ы хакыйкать»нең мөхәррире Җәүдәт Бәй төрек теленә тәрҗемә итәләр [28: 45-49]. Бу дуслык рус шәркыятьчесенә карата булган шик-шөбһәләрне дә юкка чыгара. Әхмәт Мидхәт, Фатих Кәримигә җибәргән бер хатында бу хезмәтне бик мактап телгә ала [3: 65]. Бу әсәр яңа әдәби-мәдәни эзләнү-тикшеренүләр өчен юл ача. 1890-1892 елларда А.С.Пушкинның «Буран» һәм «Пики дамасы» әсәрләре турында биографик очерк, М.Ю.Лермонтовның «Демон», Л.Н.Толстойның «Ике карт», «Гаилә бәхете», «Ильяс», «Иван Ильичның үлеме» кебек әсәрләре беренче мәртәбә төрек теленә тәрҗемә ителә. Бераздан Әхмәт Мидхәт һәм Касыйм Әминнең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткән Гөлнар ханымның алдына үз илендә цензура мәсьәләсе килеп баса [26: 156-157]. Шул ук вакытта патша Русиясендә, зур ышаныч казанып, 15 ел буе Петербург цензура оешмасында җаваплы вазифа башкарган, татар телендә китаплар чыгару яки чыгармау турында карар кабул иткән Василий Дмитриевич Смирновның [29: 523] 500 битлек «Госманлы әдәбиятының сайланма әсәрләре» хезмәте 1891елда Петербургта басыла [30: 384].

Стокгольмдагы конгресста Ә.Мидхәт Гөлнар ханым аша Казан университеты профессоры И.Готвальд белән таныша. 1857-1884 елларда Готвальд университет нәшрияты-ның директоры була, 1860-1875 елларда Казан цензура оешмасында эшли [31: 56]. Әхмәт Мидхәт 1890 елның 12 ноябрендә Фатих Кәримигә язган хатында: «Ул якларда хикмәт һәм акыл иясе Иосиф Готвальд бар, шәркыятьчеләр конгрессында танышып сөйләшкән идек. Аерым сәлам җибәрәм. Ислам белемендә гаять зур белгеч» [30: 60-61] дигән сүзләр белән аны бик мактап телгә ала.

### 7. Рухи улы – Фатих Кәрими

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, Ф.Кәримиләрнең иҗтимагый эшчәнлеге, әдәбиятка, дөньяви фәннәргә, икътисади алгарышка, дингә карата фикерләренең, хәтта әдип буларак эволюцияләренең Ә.Мидхәтнең иҗтимагый эшчәнлеге, карашлары һәм

иҗатының үсеш-үзгәрешләренә аваздаш икәнлеге күренә [8: 115].

Әхмәт Мидхәтнең Идел-Урал буе төрки халыклары арасында иң якын бәйләнештә торган һәм «рухи угълым» дип атаган кешесе Фатих Кәрими була. Ф. Кәрими моңа кадәр китаплары аша гына белгән Әхмәт Мидхәт белән 1892 елда Истанбулга килгәч шәхсән таныша һәм алга таба аның иң якын рухи дәвамчысына әверелә. Ф.Кәрими, Истанбулга килгәч, кайсы мәктәпкә уку яхшырак булуы турында фикерен белер өчен, Ә.Мидхәт янына бара. Ә.Мидхәт аңа: «Укуыгызны бетергәч, сез биредә калу фикерендәме? Яисә ниятегез, илегезгә кире кайтып, милләттәшләрегезгә хезмәт итүме? Әгәр биредә калу фикерендә булсагыз, миннән сезгә бернинди киңәш тә юк, үзегез хәл итегез. Әгәр инде илегезгә кире кайту уенда булсагыз, бу минуттан минем рухи угълым буласың, һәр төрле киңәшкә һәм ярдәмгә әзермен» [2: 98], – дип әйтә. Әхмәт Мидхәт шул көннән алып, «рухи улы» Ф.Кәрими 1896 елда укуын тәмамлаганга кадәр, һәрдаим ярдәм итеп тора. Ф.Кәрими исә, һәр җомга көнне диярлек аның янына барып, Ә.Мидхәтнең сөйләгәннәрен һәм киңәш-табышларын тыңлау шәрәфенә ирешә.

Укуын бетереп, Ялтадагы Дара татар авылында укытучы булып эшли башлаган [32: 404] Фатих Кәрими Әхмәт Мидхәт белән булган бәйләнешен өзми, аңа хатлар язып тора. 1898 елның 28 мартында язган җавап хатында Әхмәт Мидхәт аңа болай ди: «Ялтадан 1898 елның 20 март көнне язган хатыгызны укып бик нык сөендем. Беренчедән, арабыздагы хокукны (килешүне) онытмавыгызга; икенчедән, Русия мөселманнарының тәрәккыйга омтылышлары, тырышулары хакында куанычлы хәбәр бирүегезгә сөендем. Ул көнне хәтерлисезме, карантин идарәсендә сезне Мөлкия мәктәбенә кабул иттерү өчен сөйләшеп, тырышып йөри идек. Сезгә шул вакыт әйткән идем: «Бу мәсьәләдә ярдәм итәрмен, ләкин укуыгыз беткәч, биредә калу шарты белән түгел. Русиягә кире кайтып, андагы диндәшләребезгә белем һәм тәрбия эшендә хезмәт итүегез шарты белән». Әйе, моны исегездән чыгармаган булуыгызга ышанам. Чөнки, менә, биргән вәгъдәгезне тотып, кире кайтып, белем бирү эшенә керешкәнсез, Аллаһ сезне хәләл җефетегез белән бергә бәхеткә, уңышка ирештерсен» [3: 61-62].

Әхмәт Мидхәт бу хатының ахырында шактый кызыклы кисәтү дә ясый: «Безнең биредә «Жон төрек» исемле бер төркем ләгънәтнең ничек итеп азып йөрүләрен беләсез. Боларның нигилист һ.б. төрле исемнәр белән аталып йөртелүчеләре Русиядә дә бар икәнлеген ишетәбез. Бу юньсез адәмнәр үз араларына сезне дә чакырып маташырлар. Зинһар, боларны яныгызга якын китермәгез. Нәфесегезгә генә түгел, милләтегезгә дә хыянәт иткән булырсыз. Патша хәзрәтләренең һәм аның хөкүмәтенең дошманы булган бу мәлгуньнәрне яныгызга якын җибәрсәгез, патша һәм хөкүмәте каршында ышанычыгызны югалтырсыз. Бүген Истанбулда әрмәннәр һ.б. коткы таратучылар безгә ничек булып күренсәләр, сез дә анда шулай күренерсез. Сезгә, минем бу сүзләремә зур әһәмият биреп, шуннан чыгып хәрәкәт итәргә кирәк» [3: 63]. Ф.Кәриминең Ялтада яшәвен исәпкә алып, Әхмәт Мидхәт хатын болай дип тәмамлый: «Исмәгыйль Гаспринский бәк әфәнде хәзрәтләре белән хәбәрләшсәгез, сәламемне һәм олы затлары хакындагы бөек ихтирамымны белдерүегезне сорыйм. Ул бөек кешенең ислам диненә күрсәткән хезмәте дөньялыкта исеменең хәер белән искә алынуын, ахирәттә дә савабын тәэмин итәр. Шул ук теләкләрне, сезгә дә телим, угълым» [3: 63-64].

## 8. Фатих Кәриминең Истанбул сәяхәте һәм Смирновка җавабы

1899 елда атасы ахун Гыйльман Кәрими теләге белән, Кырымнан Оренбургка күчеп килгән Фатих Кәрими, шул елның 15 февралендә алтын приискалары хуҗасы Шакир Рәмиев белән Аурупа сәяхәтенә чыга. Бу сәяхәт өч ай ярым дәвам иткән. Алар Венада Истанбул поездына утыралар һәм 6 майда Истанбулга килеп җитәләр. Алар Әхмәт Мидхәт әфәнде белән гаять табигый рәвештә күрешәләр. 1902 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә Фатих Кәрими бу күрешү хакында болай дип яза: «Истанбулның мәшһүр мөхәррире мәрхәмәт иясе Әхмәт Мидхәт әфәнде хәзрәтләре янына бардык. Бугаз эченең (Босфор) Бәйкоз дигән бер мәхәлләсендә сарае бар. Анда барып үзен туры китерә алмадык. Икенче көнне Галатадагы карантин мәхкәмәсенә барып, бүлмәсендә күрешеп сөйләшүгә ирештек. Аның белән электән дә таныш идек. Мине шундук танып алды. Хуш күреп кабул итте. Шакир әфәнде белән дә таныштылар. Бу кеше – төрекләрнең

иң мәшһүр каләмияләреннән берсе, милләтенә һәм ватанына, бөтен ислам дөньясына онытылмаслык зур хезмәт күрсәткән шәхес. Роман, хикәя; фәлсәфә белеме, дин фәлсәфәсе, тарих кебек фәннәр буенча бик күп әсәрләр язган һәм аларны заман таләбенә, халкының холык-табигатенә туры китереп язганга, халыкны укуга җәлеп иткән. Әдип һаман да язуын дәвам итә, шул ук вакытта карантинда сәламәтлек идарәсендә баш сәркатип вазифасын да башкара. Әхмәт Мидхәт әфәнде хәзрәтләре турында аерым бер рисалә (брошюра) язып, бастырырга рөхсәт алыр өчен, үзенә мөрәҗәгать иткән идем. Рөхсәт бирелсә, иншаллаһ, ул да нәшер ителер. Ул вакыт, күрешеп сөйләшкәннән соң, һәрвакыттагыча, Русия мөселманнары белән бәйле нәсихәтләр бирә башлады» [32: 307-308].

Фатих Кәрими биредә Әхмәт Мидхәт әфәнде турында бер рисалә әзерләвен язган. Хаккы Тарык Ус 1944 елда Әхмәт Мидхәт әфәнденең үлеменә 100 ел тулуны искә алу җыелышында ясаган чыгышында: «Төньяк төркиләрнең язучысы Фатих Кәримов, миндә үз кулъязмасы да булган бер китабында, Әхмәт Мидхәт белән бер сөйләшүенең эчтәлеген китереп үтә» [12: 24] дип, бу рисаләне телгә ала. Әхмәт Мидхәт 1899 елның 16 июлендә Фатих Кәримигә язган озын хатында: «Истанбулдан үтеп барышлый миңа бер рисалә калдырган идегез. Мсьё Смирновның Әхвале Мөхәммәдияне тәнкыйтьләп русча язган бер мәкаләсенең тәрҗемәсе иде, монда Мөхәммәдиягә карата әйтелгән лаек булмаган фикерләргә игътибарымны җәлеп иткән идегез. Мин бу тәрҗемәне бик игътибар белән укыдым. Әхвале-Мөхәммәдия турындагы фикерләр бик өстән-өстән генә әйтелгән, җитди һәм тирән булмаган нәрсәләр. Шул дәрәҗәдә җитди түгел ки, боларны кире кагу ислам өчен бернинди кыенлык тудырмый» [3: 63-64], – дип, бер вакыйганы да искә ала. Хатның ахырында: «Максатым – сезгә Смирновның мәкаләсенә җавап яза башлаганымны белдерү иде. Әйе, бу җавап язылып ята. Эчтәлеге моңа кадәрге яклау язмаларын кабатлаудан гыйбарәт булмаячак. Аллаһының мәрхәмәте һәм шәфкате белән бирегә яңа эзләнүләремнең нәтиҗәләре керәчәк. Һәм дә бу җавап мәкаләмне Истанбулда нәшер итмәячәкмен. Моның кебек әсәрләр Госманлылар карашында инде гадилек, алар андый нәрсәләргә ияләнеп бетте. Җавап мәкаләм сезгә мөрәҗәгать итеп язылган берничә хат рәвешендә булачак. Без биредә бу хатларның берничә нөсхәсен Русия мөселманнарының иң бирелгәннәренә дә белдерәчәкбез»[3: 73]. Тик болар, Ризаэтдин Фәхретдин әйткәнчә, дини һәм гамәли мәсьәләләр түгел, ә иҗтимагый мәсьәләләр була [3: 116].

**9. Әхмәт Мидхәт һәм Ризаэтдин Фәхретдин**

Госманлы дәүләтенә нигез салган Осман бәйдән алып Мидхәт Пашага, Ибраһим Мөтәфәррикадан Кятип Чәләбигә, Фатма Халия ханымнан Нигяр ханымга кадәр Госманлының алдынгы дәүләт эшлеклеләре һәм зыялыларының биографияләрен язып нәшер иткән Ризаэтдин Фәхретдин «Әхмәт Мидхәт әфәнде» (Оренбург, 1913) китабы белән бу теманың башына таҗ кидергән кебек була.

Әхмәт Мидхәт әфәнде белән Шәмсетдин Саминең язучылык талантларын үзендә туплаган Ризаэтдин Фәхретдин, Гаисә Хөсәеновның әйтүенчә, үзе баш мөхәррире булган «Шура» журналында 180 нән артык биография язып бастыра [33: 255]. Ш.Мәрҗанинең «Вәфиятү-л әсләф» енә охшаш «Асар» исемле 4 томлык энциклопедик сүзлегендә дә аның тарафыннан 1200 гә якын биография языла [34: 185-189].

«Мәшһүр ирләр» сериясен чыгарган Р.Фәхретдин, 1913 елда, Әхмәт Мидхәтнең үлеменә 1 ел тулу мөнәсәбәте белән, бу сериянең 6 нчы китабы итеп 144 битлек «Әхмәт Мидхәт әфәнде» әсәрен Оренбургтагы Вакыт матбагасында бастыра.

Риза Фәхретдин «Әхмәт Мидхәт әфәнде» китабын, «бер ярлы егет»нең, бернинди университет яки академия бетермичә дә, бары тик үз тырышлыгы белән «тормыш мәктәбе» үтеп, олы галимнәр һәм фәлсәфәчеләр рәтенә керә алуын Идел-Урал буе яшьләренә үрнәк итеп күрсәтү теләге белән яза [3: 3]. Мәгърифәтче галим һәм язучы үзе дә әдәби иҗат белән рухланып шөгыльләнә башлаган яшьлек елларында аның тормыш юлы һәм иҗатыннан шактый гыйбрәт ала һәм аннан файдалана, шуңа күрә ул бу китапны Ә.Мидхәткә булган хөрмәтенең бер билгесе итеп нәшер итә.

Р.Фәхретдин, Ә.Мидхәт белән шәхсән күрешергә бик теләсә дә, кызганычка каршы, аның бу нияте тормышка ашмый кала. Ул бер мәсьәлә турында әдипкә кыска гына хат язып сала, әмма аның барып ирешүе хакында хәбәр алмый. Бер-берсен ишетеп кенә белсәләр дә, Әхмәт Мидхәт белән Ризаэтдин Фәхретдин,

бер-берләренә һәрвакыт сәлам әйтеп җибәрә торган булалар. Якыннан аралаша алмасалар да, Риза Фәхретдин зур хөрмәт белән: «Аны яратуыбызны һәм аның белән рухи бәйлелегебезне соңгы сулышыбызгача дәвам иттерәчәкбез» [3: 4], – дип белдерә. 1905 елның 14 сентябрендә туганының баласы Фатих Кәримигә җибәргән үзенең тәрҗемәи хәлендә Шәмсетдин Сами турында да түбәндәге юлларны язган: «Шәмсетдин Сами белән күрешеп фикер алышырга теләсәм дә, бу теләгем тормышка ашмый калды. Югыйсә, аның әсәрләреннән, фәлсәфәсеннән шактый файдаланган идем» [16: 37].

Ризаэтдин Фәхретдин үзенең романнары («Сәлимә, яки гыйффәт», Казан, 1899; «Әсма, яки гамәл вә җәза», Оренбург, 1903), нәсихәтләре («Тәрбияле ана», Казан, 1898; «Тәрбияле ата», Казан, 1898; «Тәрбияле бала», Казан, 1889), дини, иҗтимагый һәм тарихи әсәрләре белән Ә.Мидхәт әфәндене, ә «Мәшһүр хатыннар» (Оренбург, 1903) һәм 4 томлык «Асар»е белән Шәмсетдин Самине хәтерләтә. Ризаэтдин Фәхретдин 1880 елларда Ә.Мидхәт әфәнденең күп әсәрләрен тәрҗемә итеп, бастырыр өчен, нәшриятларга биреп тә, аларның юкка чыгулары һәм «Тәрбияле бала» әсәрен Әхмәт Мидхәтнең «Тәрбияле бала» әсәренә ияреп язуы турында да белдерә [3: 123].

## 10. Кабер ташына «Сай' у Себат» дип язылсын

Ризаэтдин Фәхретдин, Әхмәт Мидхәтнең әсәрләрен яратып, кат-кат укучылар турында язганда, исән булганнарның исемнәрен үз хезмәтләрендә телгә алмаска тырышкан. Әхмәт Мидхәт үзенең аңлаешлы гади тел, заманга ярашлы тулы аңлатмалар белән язылган әсәрләре һәм бу төбәк зыялылары белән шәхсән аралашуы сәбәпле, Идел-Урал буенда киң танылган һәм яратып укылган бердәнбер госманлы язучысы булып әверелә. Ныклы белеме, хезмәтләре белән ислам дөньясында шөһрәт казанган Шиһабетдин Мәрҗани дә, Әхмәт Мидхәтнең «Мөдафага»ларын укыгач, аларны бик ошатуын һәм хуплавын белдерә [3: 121]. «Мөдафага»лар гына түгел, «Каинат» дигән тарих китаплары да Русия мөселманнарында шактый кызыксыну уяткан. Әхмәт Мидхәтнең «Ләтаиф-и риваять», «Илһамат вә тагълитат», «Бәшир Фуат», «Шопенның тормышы һәм һөнәре», «Фатма Халия Ханым» кебек әсәрләре дә шактый киң таралган була [2: 97]. Тышына Әхмәт Мидхәт дип язылган әсәрләр тиз арада сатылып бетә торган булган. XIX-XX гасыр чикләрендә төрек-татар әдәби бәйләнешләрен тикшергән Р.Харрасова болай дип яза: «Беренче рус революциясе алды унъеллыгы прозасындагы тәрҗәмәләрне тулаем караганда, аларның иң күбесе Әхмәт Мидхәттән икәнлек күренә. Бу исә үз чиратында, аның иҗатының Яңа заман әдәбиятыбызның чишмә башында торуын ишарәли» [8: 114 ].

Әсәрләре һәм шәхесе белән Идел-Урал буена шул дәрәҗәдә йогынты ясаган Ә.Мидхәт әфәнденең вафаты биредәге халыкны тирән кайгыга салган. Русларның Лев Толстоена охшатылган Ә.Мидхәт үлеменнән соң Госманлы төрекләренең аңа тиешле дәрәҗәдә игътибар бирмәве шактый тәнкыйть ителә. Әдипнең вафаты көннәрендә Истанбулда булган «рухи угълы» Фатих Кәрими дә аның җеназасында катнаша.

Ризаэтдин Фәхретдин монографик хезмәтен «Алты йөз еллык тарихы дәвамында Төркия хөкүмәте бик аз санлы галимнәрнең берсе булган Әхмәт Мидхәт әфәнденең кабер ташына Әхмәт Мидхәт дип түгел, Сай' у Себат[3] дип язылсын» [3: 137] дигән сүзләр белән тәмамлый.

Димәк, XIX гасырның икенче яртысында яңа төрек прозасына, халыкның иҗтимагый-сәяси карашларын формалаштыруда зур роль уйнаган вакытлы матбугатка нигез салган, бертуктаусыз аң-белем, мәгърифәтчелек идеяләрен яклаган һәм пропагандалаган Әхмәт Мидхәт әфәнде исеме һәм күпъяклы эшчәнлеге Русия мөселманнарына яхшы таныш була. Күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, педагог-тәрбияче һәм мәгърифәтче Әхмәт Мидхәт Идел-Урал буе татарларының әдәби-мәдәни алгарышына, иҗтимагый-фәлсәфи фикере үсешенә, милли мәгарифе яңарышына, рухи тормышы күтәрелешенә турыдан-туры йогынты ясый һәм аның тәэсирендә гомерләрен халыкка хезмәткә багышлаган татар зыялыларының яңа бер буыны барлыкка килә.

**Әдәбият**

1. *Мидхәд Ә.* Яшьлек җүләрлек / Тәрҗемәче С.Максуди. Казан, 1897. 30 б.; Кыйссадан хисса. Казан: Борадәран Кәримевләр нәшрияты, 1902. 30б.; Яшь егетләр өчен гаять файдалы бер хикәят. Оренбург, 1902. 40 б.; «Бозу»дан дару һәм мәшһүр төрек философы Әхмәт Мәхмүтнең

[3] Сай′ у Себат- тырышлык вә ныклык

«Хыял вә хакыйкать» нам әсәренең тәрҗемәсе / Тәрҗемәче Ш.Мостафа. Казан, 1908. 51 б.
2. *Kerimi F.* Ahmet Mithat Efendi ve Şimal Türkleri // Türk Yurdu, 1912, sayı 30, sh. 97. (төрек телендә).
3. *Фәхретдин Р.* Әхмәт Мидхәт әфәнде. Оренбург: Вакыт матбагасы, 1913. 144 б.
4. *Ибраһимов Г.* Әдәбият мәсьәләләре // Әсәрләр сигез томда. 5 том: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). Казан: Тат. кит. нәшр.,1978. 18-37 б.; «Без – татарбыз» // Әсәрләр. 8 томда. 7 том: Тарихи хезмәтләр (1911-1927). Казан: Татар. кит. нәшр.,1984. 5-10 б.; «Рус, төрек вә татар тарихыннан» // Йолдыз. 1913. 17 март; «Милли тарих» // Йолдыз. 1912. 8, 12, 17 апрель.
5. *Бәдигъ Т.* Әхмәд Мидхәт әфәнде // Йолдыз. 1912. 25 декабрь; Камал Г. Мәрхүм Әхмәд Мидхәт әфәнде // Йолдыз. 1912. 23 декабрь һ.б.
6. *Магдеев М.* Социальные корни таланта. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 158 с.
7. *Миңнегулов Х.Й.* Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики): монография. – Казань: Изд-во КГУ, 1993. 384 с.; Татар-төрек әдәби багланышлары // Татарстан. 1993. №9. 50-56 б.; Этапы развития тюрско-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас. 2014. 288 с.
8. *Харрасова Р.Ф.* Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан: «РПФ «Гарт» нәшр., 2002, 261 б.
9. *Нигматуллина А.М.* Татарско-турецкие литературные связи конца XIX – начала XX века (на материале жизни и творчества турецкого писателя-просветителя Ахмета Мидхата): Автореферат дис. … кан. филол. наук. Казан, 2001. 23 с.
10. *Мухаметов И.* Книга Мухаммеда Челеби «Мухаммадия» в контексте татарско-турецких литературных взаимосвязей: Автореферат дис. ... канд. филол. наук. Казан, 2006. 22 с.
11. *Velidi Togan Z.* Hatıralar. Ankara: Türk Diyanet Vakfı Yay, 1999, sh.82. (төрек телендә).
12. Mithat'ı Anıyoruz. Haz.: Hakkı Tarık Us. İstanbul,1955, sh.76. (төрек телендә).
13. *Hamdi Tanpınar A.* 19. Asır Türk Edebiyatı Tarihi. İstanbul: Çağlayan Kitapevi, 1988, sh.472. (төрек телендә).
14. *Муашака яһуд Талат Бәг илә Фитнат Ханым.* Тәрҗемәче: Инаятуллаһ Әхмади Хәзрәт угълы Айдаров. Оренбург, 1904. (Уфа. Әхмәтзәки Вәлиди китапханәсе. Борынгы әсәрләр бүлеге. № 28966).
15. *Шәмсетдин Сами бәк* Хатыннар / Төрекчәдән тәрҗемә. Оренбург: Бреслин, 1899 64 б.
16. *Ризаэтдин Ф.* Фәнни-биографик җыентык. Казан: Рухият, 1999, 224 б.
17. *Махмут Сатаев Г.* Әхмәт Мидхәт әфәнде // Шура, 1913, №2, 38-40 б.
18. *Ризаэтдин Ф.* Болгар һәм Казан төрекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993, 287 б.
19. *Госманов М.* Каурый каләм эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994, 463 б.
20. *Кәримуллин Ә.* Беренче татар китаплары // Казан утлары, 1967, №5, 126-134 б.
21. *Фәхретдин Р.* Ибраһим Мөтәфәррика // Шура, 1913, №14, 417-418 б.
22. *Фәхретдин Р.* Шәйх Зәйнулла хәзрәтенен тәрҗемәи хәле. Оренбург, 1917, 106 б.
23. *Фәхретдин* Р. Исмагыйль сәяхәте. Казан: Табгъ Бимасаров мәктубат-ы шәркыя, 1903. 32 б.
24. *МиңнегуловХ.* Дөньяда сүзебез бар… Казан: Татар.кит.нәшр., 1999, 336 б.
25. *Кәримуллин Ә.* Язмыш, язмыш… Казан: Татар. кит. нәшр., 1996, 423 б.
26. *Кәримуллин Ә.* Китап дөньясына сәяхәт: (Татар басма сүзенең сәхифәләреннән). Казан: Татар. кит. нәшр.,1979. 208 б.
27. Carter V. Fındley, A. Mithat Efendi Avrupa'da. İstanbul: Tarih Vakfı Yurt Yayınları, 1999, sh.22-23. (төрек телендә.)
28. *Кәримов Г.* Яңа Госманлы әдәбияты // Шура, 1911, №2, 45-50 б.
29. *Смирнов Василий Дмитриевич* // Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1999, 523с.
30. *Кәрими Ф.* Госманлы әдәбияты // Шура, 1908, №12, 384-386 б.
31. *Готвальд Иосиф Федорович* // Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1999, 56 с.
32. *Кәрими Ф.* Аурупа сәяхәтнамәсе // Мирза кызы Фатыйма. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996, 150-310 б.
33. *Хөсәенов Г.* Ризаэтдин бин Фәхретдин. Уфа: Китап, 1997, 255 б.
34. *Мөхәммәтҗанов А.А.* Мәрҗани, тарих һәм хәзерге заман // Ш.Мәрҗанинең «Вафиятү-л әслаф…»ы һәм Р.Фәхретдиннең «Асар»е. Халыкара фәнни конференциясе материаллары. Татарстан Фәннәр Академиясе, Тарих институты. Казан, 1998, 185-189 б.

# АХМЕТ МИДХАТ И ТЮРКИ ИДЕЛЬ-УРАЛА

**Хусаен Барган,**
Стамбульский университет, Центр языка,
Турция, 34452, г.Стамбул, Баязит Фатих,
huseyinbargan@yahoo.com

**Тагир Шамсегалиевич Гилазов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, 18
tgilazov@bk.ru

В статье рассматриваются тюрко-татарские литературные и культурные взаимосвязи конца XIX – начала XX века. В этот период десятки представителей татарской интеллигенции получают высшее образование в учебных заведениях Турции и начинают изучать пути обновления общественно-культурной жизни. Их устремления находят отклик среди передовой турецкой интеллигенции. Имя турецкого писателя, ученого, философа, издателя и общественного деятеля Ахмета Мидхата широко известно в России среди тюрок-мусульман Идель-Урала, в связи с этим его имя пользовалось популярностью у татар. Идеи А.Мидхата оказали неоценимое влияние на развитие татарской общественной и религиозно-философской мысли, национального словесного творчества, прогрессивных экономических процессов. Он взял под свое покровительство Ф.Карими во время пребывания писателя в Турции и способствовал формированию его разносторонне образованной личности. В татарской печати начала XX века периодически публикуются статьи о жизни и деятельности А.Мидхата. Особую активность в этом направлении проявляют Ф.Карими и Р.Фахретдин. Кроме публикаций в журнале «Шура» и газете «Вакыт», его деятельность получает высокую оценку в монографических трудах.

**Ключевые слова:** Идель-Урал, культурные взаимосвязи, турецкая литература, периодическая печать, востоковед, литературное произведение, перевод.